КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 10 июнь г.Казань № 546

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1141 нче; 2020 ел, 13 июль, 584 нче, 2021 ел, 31 май, 408 нче, 2022 ел, 11 февраль, 114 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Эш бирүчеләр экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска.»;

2.4 пунктның икенче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

3.2 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүче тарафыннан субсидия бирү тәртибе, аны кире кайтару сроклары, әлеге Тәртипнең шартларын үтәү турында нигезләмәләр һәм Субсидия бирү турында төзелә торган килешү, Субсидия бирү турында килешү шартларын бозган өчен җаваплылык, эш бирүченең аңа карата субсидия бирү шартлары һәм тәртибенең үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне тикшерүләр;»;

4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Министрлык эш бирүчеләрнең субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә, үтәвен тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

4.5 пунктның беренче абзацында «максатлар» сүзен төшереп калдырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенең 2.3 пунктындагы өченче абзацның гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин